РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕАТРЯССКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 58-3-05, факс 58-3-05

# КАРАР

**1 ноябрь 2019 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Зур Әтрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Кече Әтрәч авыл Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Кече  Әтрәч авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;

- Кече Әтрәч авылында лампалар, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;

- Кече Әтрәч авылында Тукай ур., Советская ур. Юлларны төзекләндерү;

- Кече Әтрәч авылы зираты территориясен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Зур Әтрәч авыл җирлеге башлыгы** **И.Ш. Юнусов**